| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06. 04. 2023 с.Старое Дрожжаное № 161

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» 2013 елның 9 сентябрендәге 679 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 февралендәге 100 номерлы карары нигезендә, Чүпрәле муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында»гы 2013 елның 9 сентябрендәге 679 номерлы (31.01.2014 № 59, 12.02.2014 № 88, 10.02.2017 № 78, 24.08.2017 № 463, 19.10.2017 № 591, 21.12.2017 № 707, 22.08.2019 № 364 ред.) карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.3 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча гаиләнең җан башына туры килә торган уртача керем компенсациясе алуга хокукны билгеләгәндә исәпләп чыгарыла;

**2.1 пунктында** «12 айның соңгы алты ае» сүзләрен «соңгы 12 календарь айга» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Ф. Җәләловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов